МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.11.2022 Казан шәһәре № 390

**«Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәткәрләргә эш хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган башка максатларга субсидияләр өлешендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының дүртенче абзацы, «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында» 2021 елның 09 октябрендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә **боерам**:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәткәрләргә эш хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган башка максатларга субсидияләр өлешендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (аңа карата гамәлгә

куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүнең кушымта итеп бирелә торган тәртибен расларга

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә әлеге боерыкны теркәгән көннән алып бер эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Икътисад министрының беренче урынбасары О.В. Пелевинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
_____________ ____ номерлы
боерыгы белән расланды

**«Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәткәрләргә эш хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган башка максатларга субсидияләр өлешендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәткәрләргә эш хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган башка максатларга субсидияләр өлешендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Учреждение), (аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр (алга таба – башка максатларга субсидияләр) бирүнең максатын, шартларын һәм тәртибен, шулай ук башка максатларга субсидияләр бирү күләмен билгеләү шартларын һәм тәртибен, хисаплылыкка таләпләрне, башка максатларга субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту тәртибен һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны билгели.

1.2. Башка максатларга субсидияләр Учреждениегә «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча Учреждение хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә.

«Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәт хакы түләү Учреждение хезмәткәрләренә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле

дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яисә) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда бюджеттан тыш дәүләт фондларына билгеләнгән салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен һәм бүтән мәҗбүри түләүләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча Учреждение хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү кадрлар потенциалын саклап калуны һәм Учреждение хезмәткәрләренә хезмәт хакын арттыруны тәэмин итә.

1.3. Татарстан Республикасы бюджет акчаларын баш бүлүче – Учреждениегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, аңа Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, бюджет акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына башка максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән (алга таба – Гамәлгә куючы).

1.4. Башка максатларга субсидияләр Учреждениенең түбәндәге чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә бирелә:

Учреждение хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр.

## 2. Башка максатларга субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирү әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре, тиешле финанс елына башка максатларга субсидияләр бирүгә бюджет акчаларын алучы буларак Гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Гамәлгә куючы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Башка максатларга субсидияләр алу өчен, Учреждение Гамәлгә куючыга түбәндәге документларны бирә:

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта белән расланган форма буенча башка максатларга субсидияләр алу өчен гариза;

башка максатларга субсидияләр алу өчен гариза биргән вакытка гамәлдә булган хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча Учреждениенең штат расписаниесе;

Учреждениенең яңа хезмәт хакы системасына күчү вакытында гамәлдә булган штат расписаниесе;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчалары бирү зарурлыгын нигезләүне, башка максатларга субсидияләр суммасын исәпләүне – нигезләүне дә кертеп, үз эченә алган аңлатма язуы, шулай ук Учреждениенең «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча түләүләрне алучы хезмәткәрләренең фаразлана торган саны турында мәгълүмат;

салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча бурычының үтәлеше турында гариза бирү планлаштырыла торган айның беренче числосына салым органы тарафыннан бирелгән, «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча бурычының үтәлеше турында белешмә формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау турында» Федераль салым хезмәтенең 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча белешмә;

гариза бирү планлаштырыла торган айның беренче числосына бирелгән, учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү буенча чараларны тормышка ашыру, һәлакәтне (гадәттән тыш хәлләрне) булдырмау, һәлакәт (гадәттән тыш хәл) килеп туган очракта, нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, закон көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычларны каплау өчен башка максатларга субсидияләр бирү очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш, Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, кичектерелгән бурычлары булмау турында Учреждение җитәкчесе һәм баш хисапчы, башка вәкаләтле зат имзасы белән белешмә.

Тапшырыла торган документлар аңлаешлы итеп бастырылырга тиеш. Учреждение мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләтле зат имзасы белән расланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан кулдан расланган төзәтүләрдән кала, чистарту һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Документларның күчермәләре Учреждение мөһере белән беркетелергә һәм моңа вәкаләтле затның имзасы белән расланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан кулдан расланырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язмача мөрәҗәгате Учреждение мөһере белән беркетелергә һәм моңа вәкаләтле затның имзасы белән расланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан кулдан расланырга тиеш.

2.3. Башка максатларга субсидияләр алу өчен документлар Гамәлгә куючы тарафыннан кергән көнне журналга теркәлә, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән соң биш эш көне эчендә аларны карый, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм башка максатларга субсидияләр бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел) ;

әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

Документларны тулы комплектта тапшырмаган һәм (яки) тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры

килмәгән очракта, шулай ук Учреждение тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүмат дөрес булмаган очракта, Гамәлгә куючы әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланганнан көннән соң ике эш көне эчендә, документларны кире кайтару сәбәпләре турында язмача хәбәр итеп, аларны Учреждениегә кире кайтара. Учреждение, документларны кире кайтаруның сәбәпләрен бетергәннән соң, документларны кабат җибәрергә хокуклы.

2.4. Гариза бирелә торган айның беренче числосына Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле үтәлмәгән бурычлары булмау;

(учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү буенча чараларны тормышка ашыру, һәлакәтне (гадәттән тыш хәлләрне) булдырмау, һәлакәт (гадәттән тыш хәл) килеп туган очракта нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, закон көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычларны каплау өчен субсидияләр бирү очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш) Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, кичектерелгән бурычлары, дәүләт ярдәменең башка төрләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты алдында кичектерелгән бүтән бурычлары булмау.

2.5. Башка максатларга субсидияләр күләме әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә учреждение тарафыннан бирелгән документлар һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре, тиешле финанс елына башка максатларга субсидияләр бирүгә бюджет акчаларын алучы буларак Гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән расланган бюджет ассигнованиеләре нигезендә билгеләнә.

Башка максатларга субсидияләр бирү буенча бюджет ассигнованиеләре күләмен билгели торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелгән очракта, башка максатларга бирелә торган субсидияләр күләме үзгәртелергә мөмкин.

2.6. Башка максатларга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә Гамәлгә куючы һәм Учреждение арасында «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типлаштырылган формасын раслау хакында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең типлаштырылган формасына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 17-131 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча субсидияләр бирү турында түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алган килешү (алга таба – Килешү) төзелә

башка максатларга субсидияләр бирү максаты;

башка максатларга субсидияләр күләме;
башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;
башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренең кыйммәте;
башка максатларга субсидияләр күчерү вакытлары;
хисап тапшыру вакытлары;
өстәмә хисап (кирәк булганда);
Учреждение Килешүдә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәгән очракта, башка максатларга субсидияләр суммаларын кире кайтару тәртибе һәм вакыты;
Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән башка максатларга субсидияләр бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Гамәлгә куючыга киметкән очракта;
башка максатларга субсидияләр күләмен үзгәртү нигезләре һәм шартлары;
Килешүне берьяклы тәртиптә Гамәлгә куючы карары буенча, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә вакытыннан алда туктату өчен нигезләр:
Учреждениене үзгәртеп кору яки гамәлдән чыгару;
Учреждениенең башка максатларга субсидияләр бирү максатларын һәм шартларын бозуы;
Учреждение тарафыннан Килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю;
Гамәлгә куючы билгеләгән башка нигезләмәләр (кирәк булганда).
2.7. Гамәлгә куючы, башка максатларга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирү өчен Гамәлгә куючыга җиткерелгән финанслауның иң чик күләмнәре күләмендә башка максатларга субсидия күчерә.
Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирү өчен Гамәлгә куючыга җиткерелгән финанслауның иң чик күләмнәре күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләреннән, бюджет йөкләмәләре лимитларыннан кимрәк булган очракта, калганын күчерү башка максатларга субсидияләр бирүгә финанслауның иң чик күләмнәре калдыгын Гамәлгә куючыга җиткергән көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.
2.8. Учреждениегә бирелгән башка максатларга субсидияләр акчалары белән операцияләр Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган аерым шәхси хисапларында исәпкә алына.
2.9. Учреждениенең финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы башка максатларга субсидияләр булган чыгымнарын санкцияләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
2.10. Агымдагы финанс елы дәвамында башка максатларга субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны өстәмә финанслау кирәк булган очракта, Учреждение, өстәмә финанс ресурслары кирәклегенә дәлил – исәп-хисап тапшырып, башка максатларга субсидияләр күләмен арттыру тәкъдиме белән Гамәлгә куючыга мөрәҗәгать итә ала.
2.11. Учреждение башка максатларга субсидияләр күләмен арттыру турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать иткән очракта, Гамәлгә куючы, кергән мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә, Учреждениенең әлеге тәкъдимен һәм өстәмә

финанс чаралары бүлеп бирү кирәклеген дәлилләгән исәп-хисапны карый, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә өстәмә килешүләр төзү юлы белән Килешүгә үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыга.

2.12. Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсе булып Учреждение хезмәткәрләренә башка максатларга бирелгән субсидияне 100 процент күләмендә башка максатларга субсидия бирүнең елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча түләү суммасы тора.

## 3. Хисапка таләпләр

3.1. Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең типлаштырылган формасына кушымта формалары буенча Гамәлгә куючыга, раслый торган документларны кушп, түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып башка максатларга субсидияләр торган чыгымнар турында хисап, башка максатларга субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча.

башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре кыйммәтенә ирешү турында хисап, башка максатларга субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча.

Учреждение Гамәлгә куючыга әлеге Тәртипкә кушымта итеп бирелә торган форма буенча түбәндәгеләрне тәкъдим итә (2 нче кушымта):

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап (4 нче квартал өчен хисап башка максатларга субсидияләр бирү елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча тапшырыла).

3.2. Бюджет акчалары керүнең һәм тотылышының бюджет (бухгалтерлык) исәбе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алып барыла.

## 4. Башка максатларга субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

4.1. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органы Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен мәҗбүри рәвештә тикшереп тора.

4.2. Учреждение башка максатларга субсидияләр алу өчен яки башка максатларга субсидияләрдән файдалану турында дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар биргән өчен, башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен, шулай ук башка максатларга субсидияләрне тоту максатларын бозган өчен, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән хисапны тапшырмаган өчен, башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән өчен әлеге Тәртип нигезендә җавап тота.

4.3. Хисап финанс елында кулланылмаган башка максатларга субсидияләр калдыклары, хисап финанс елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш, Гамәлгә куючы тарафыннан әлеге акчаларга ихтыяҗ булу турында Карар кабул итү очракларыннан тыш.

Хисап финанс елында кулланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрү ихтыяҗы булган очракта, Учреждение Гамәлгә куючыга, хисап финанс елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, мондый ихтыяҗны дәлилләп, мәгълүмат тапшыра.

Гамәлгә куючы, Учреждениедән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча, агымдагы финанс елында Учреждениенең хисап финанс елында кулланылмаган башка максатларга субсидияләр калдыгын башка максатларга юнәлдерүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында бюджет законнары нигезендә карар кабул итә.

Гамәлгә куючы тарафыннан агымдагы финанс елында Учреждениенең хисап финанс елында кулланылмаган башка максатларга субсидияләр калдыгын башка максатларга юнәлдерүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар кабул ителгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта Гамәлгә куючы белән Учреждение арасында килешүгә өстәмә килешү төзелә.

Әлеге Тәртипнең әлеге пунктында күрсәтелгән башка максатларга субсидияләр калдыкларын кире кайтару срокларын бозу очракларында, Гамәлгә куючы, башка максатларга субсидияләрне, башка максатларга субсидияләр калдыкларын кире кайтару срогы чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

4.4. Башка максатларга субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу очраклары ачыкланган очракта, Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс тикшерүе органы күрсәтелгән фактны ачыклаганнан соң 10 эш көне эчендә Учреждение адресына  башка максатларга субсидияләр акчаларын кире кайтару турында язма таләп җибәрә.

Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс тикшерүе органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә башка максатларга субсидияләр бирү һәм алардан файдалану буенча хокук бозуларны ачыклау очрагында, башка максатларга субсидияләр күрсәтелгән фактны ачыклаганнан соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Билгеләнгән вакыт эчендә акча кермәгән очракта, Гамәлгә куючы Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны суд тәртибендә түләттерү буенча чаралар күрә.

4.5. Килешүдә күрсәтелгән башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, башка максатларга субсидияләр Учреждениегә Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс контроле органы тарафыннан тиешле таләп куелганнан соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.6. Агымдагы финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы булып башка максатларга субсидияләр булган Учреждение тарафыннан элек түләнгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акча булганда, Гамәлгә куючы Учреждение тарафыннан, әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен, аларны

куллану турында финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, Учреждение тарафыннан элек түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акча торган үтәлмәгән йөкләмәләрнең булуы турында башка максатларга субсидияләр бирү елыннан соң килә торган елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән Учреждение мөрәҗәгате, шулай ук Учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләренең булу-булмавын һәм күләмен (физик затларга түләүләр буенча бурычлардан тыш) раслый торган документлар (документлар күчермәләре) нигезендә карар кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында, әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен, Учреждение тарафыннан элек башкарылган финанс белән тәэмин итү чыганагы булып башка максатларга субсидияләр булган түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне файдалану турында Учреждениенең элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан алынган акчалар буенча мөрәҗәгате алынган көннән биш эш көне эчендә карар кабул итә.

«Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәткәрләргә эш хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган башка максатларга субсидияләр өлешендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

**20___ елның «____» _______________ башка максатларга субсидияләр алу өчен 20_____ елның «____» __________ ____ номерлы**

**гариза**

_______________________________________________________________________

(учреждение исеме, ИНН/КПП)

_______________________________________________________________________

(башка максатларга субсидияләр төре)

| т/б № | Максатчан статьяның исеме | Чыгымнарның бюджет классификациясе коды | Башка максатка субсидияләрне тотуның максатчан юнәлеше | Агымдагы финанс елына соратып алына торган башка максатларга субсидияләр суммасы, сум. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| Гариза буенча БАРЛЫГЫ | | | | |

Әлеге гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

_______________________________________________________________________

Учреждение җитәкчесе ____________________________ /                              /

Учреждениенең баш хисапчысы _______________________ /                              /
М.У.

«Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2021 елның 09 декабрьендәге 1206 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткә түләүнең яңа системасы буенча хезмәткәрләргә эш хакын түләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган башка максатларга субсидияләр өлешендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә (контроль нокталарга) ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында 20 __ елның «__» _______ торышы буенча хисап (1)

| | | КОДЛАР |
|---|---|---|
| Алучының исеме ________________________ | җыелма реестр буенча<br>ИНН | |
| Дәүләт хакимиятенең башкарма органы – Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең исеме ________________________ | җыелма реестр буенча | |
| Документ төре ________________________<br>(беренчел – «0», аныкланган - «1», «2», «3», «...»)<br>Периодик рәвештә кабатланып тору: айлык, кварталлык, еллык | | |
| Үлчәү берәмлеге: сум. | ОКЕИ буенча | 383 |

| Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | Кыйммәте | | | Ирешү вакыты | | Статус (5) | Тайпылыш сәбәбе (6) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | коды | тибы | исеме | ОКЕИ буенча коды | планлы | фактагы (2) | фаразлаулы (3) | планлы | фактагы (фаразлаулы) (4) | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре (7) | | | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль нокталары (8) | х | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| план чорының контроль нокталары (9) | х | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Алучының җитәкчесе (вәкаләтле зат)

_____________________________________________ _________________________

(вазыйфа) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Башкаручы _____________________________________________ _________________________

(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза)

«___» _____________ 20__ ел

(1) Хисап күрсәткечләре пландагы күрсәткечләргә ирешү вакыты хисап датасына килеп җиткән башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре, контроль нокталар турында, пландагы күрсәткечләре узган хисап чорларында ирешүгә планлаштырылган башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләрен, контроль нокталарны да кертеп, шулай ук ирешү вакыты хисап чорыннан соңгы өч ай эчендә планлаштырылган башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре, контроль нокталар турында мәгълүмат нигезендә формалаша. Килешүдә дәүләт серен яисә федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый

актлары нигезендә саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүмат тупланган очракта, тиешле билге («эш буенча куллану өчен» / «яшерен» / «аеруча яшерен» / «махсус әһәмияттәге») һәм экземпляр номеры куела.

(2) Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенең һәм 1 нче графада урнаштырылган контроль нокталарның фактта ирешелгән кыйммәте күрсәтелә

(3) Башка максатларга субсидияләр бирнең тиешле хисап датасына ирешү вакыты җиткән нәтиҗәсенең 1 нче графада билгеләнгән күрсәткеченең һәм контроль нокталарның фактта ирешелгән, 6 графада күрсәтелгән план күрсәткеченнән тайпылышы күрсәтелә.

(4) Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенә, 1 нче графада урнаштырылган контроль ноктага ирешү вакыты күрсәтелә. Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенең, 6 нчы графада билгеләнгән контроль нокта кыйммәтенә хисап чорында ирешелмәгән (өлешчә ирешелгән) очракта, билгеләнгән дәрәҗәгә ирешүнең фаразланган вакыты күрсәтелә.

(5) «О» статусы – тайпылышлар булмау, «1» – тайпылышлар булу күрсәтелә.

(6) Билгеләнгән датага башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенең пландагы кыйммәтенә, контроль ноктага фактта ирешелмәгән очракта, пландагы кыйммәттән тайпылуның сәбәбе күрсәтелә.

(7) Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенең исеме күрсәтелә.

(8) Хисап чорында ирешү датасы килеп җиткән контроль ноктаның исеме күрсәтелә.

(9) Хисап чорыннан соңгы өч ай эчендә ирешү планлаштырылган контроль ноктаның исеме күрсәтелә.